| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨТӘШКӘ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **Нагорная ул., 99а с.Утяшки, 422514** | **Нагорная ур., 99а Өтәшкә ав, 422514** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 2 феврале** **№ 1**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»гы 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары нигезендә Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитеты **карар итә:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Өтәшкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 2023 елнын 31 гыйнварындагы 1 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Өтәшкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорт (СДК бинасы) урнаштырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы А.А. Клопов

Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 2 феврале №1 карарына 1 нче кушымта

ТР Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегендә 2024 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4561,35 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 1299,37 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2509,48 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |

Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 2 феврале №1 карарына 2 нче кушымта

ТР Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегендә 2024 елнын 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне төрү | 805,88 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 755,48 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка ташу | 1 299,37 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 2 509,47 |
| **Барлыгы** | **8 370,20** |